СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

17 гыйнвар, 1997 ел. ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 5 (8017) | Бәясе билгеләнгәнчә



Рәхмәт яугыры

9 гыйнварда Татарстаннан Бакыга гуманитар ярдәм белән автомашиналар колоннасы килде. Әлеге ярдәм Карабахта булган низагта яшәүгә чарасыз калган әзербәйҗан кардәшләребезне имин килеш саклау өчен оешдырылды. Әлеге изге нигезгә ике илнең илбашлары узган елның ноябрь очрашуында Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев нигез салган иде.

Җиребездә рәхмәтле бәндәләр

Башкалабызга Рамазан ае уңаеннан Төркиядән 15 имам килеп төште. Алар Аллаһы Тәгаләгә иң якын торган изге айны Татарстанда яшәүче мәселман кардәшләре белән бергә үткәрәчәк һәм мәчет - мәдрәсәләрдә вәгазләр сөйләячәк. Игелек ияләренә Аллаһының рәхмәте булсын!

Күп балалылар онытылмый

Татарстан Җөмһүриятендә күп балалы гаиләләрне социаль яклауны көчәйтү чаралары хакында республика хөкүмәте карар кабул итте. Шунысы аерым игътибарга лаек: 16 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләүчеләр Россия Федерациясендә хезмәткә минималь түләү күләмендә компенсация алачаклар. Стипендия алмаучы 18 яшькә кадәрге студентлар да бу җәһәттән исәпкә кертелә.

Чаллы: завод «уянды»

«КамАЗ» акционерлык җәмгыятенең двигательләр заводында төп конвейер эшли башлады. Мәгълүм булганча, завод 3 ел элек нигезенәчә яныш беткән иде.

БАЛАЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

Мәктәпне тәмамлагач ук читкә чыгып китте Фәнилә. Эшкә урнашты, бер үк вакытта читтән торып Алабуга дәүләт педагогия институтында да укыды. Эше дә җиңел бирелде, укуы да көйле барды. Ата - анасы күңеленә салган шәхси җаваплылык, тормышта юл ярып барырга өйрәтү яшьли төп яшәү маягына әверелде аның. Яр Чаллы шәһәрендә иң көчлеләрдән саналган 28 нче мәктәп - гимназиядә эшкә урнашуы һәм инде үзен балалар күңеленә ачкыч табып, иҗади эшләүче укытучы итеп таныта алуы, гади педагогтан укыту эшләре мөдире булып житешүендә дә иң беренче чиратта максатчан булуы, шәхси тырышлыгы зур роль уйнады.

Шулай туры килде инде, Чаллыда бер дистәдән артык ел эшләгән Фәнилә кире туган җире - Әмзәгә әйләнеп кайтты. Хәзер инде ул югары белемле, тәҗрибәле педагог, ир хатыны, балалар анасы. Үзе укып белем алган мәктәптә күңеленә якын эш тә тапты ул. Фәнилә Сәетовна башта берничә ел башлангыч классларда укытты. Быелгы уку елыннан ул мәктәп директорының укыту эшләре буенча урынбасары. Беренче вакытта башлангыч классларда рус теле укыта.

- Искиткеч намуслы, эшенә чын күңелдән бирелгән кеше ул,- ди аның турында мәктәп директоры Р.Нигъмәтуллина да.

Рәсемдә: Яңа Әмзә урта мәктәбе укытучысы Ф.С.ӘХМӘДИЕВА.

Н.АЗИЗОВ фотосы.

Уйланырлык урын бар

1996 елда Октябрь район халык судында каралган жинаять эшләре саны үткән елгы 335тән 346 га үсте. Гражданнар эше 416 га житте. 399 кеше төрле җәзага хөкем ителгән, шул исәптән 74се төрле срокларга ирегеннән мәхрүм ителгән. Күпчелек өчен хөкем карары кичектерелде, сынау вакыты белән шартлы рәвештә хөкем ителде, төзәтү эшләре яки штраф рәвешендә җәза бирелде. Аннан тыш, ел агымында суд административ характердагы 1286 эш карады. Алар вак хулиганлык, бурлык, законсыз сәүдә итү һәм башка фактларга бәйле.

КАР - БУРАННАР КУРКЫТМАС

Быел гыйнвар салкын һәм аяз булды. Ләкин бу безне кар - буранннардан котылдырды дигән сүз түгел әле. Һичшиксез, буранны да, кар көртләре дә булачак. Бу очракта районда 450 километрлап исәпләнгән автомобиль юлларының торышы нинди-ерәк булачак? Безнең корреспондентыбызның әлеге соравына юллар торышы өчен җаваплы итәшләр түбәндәгеләрне хәбәр иттеләр.

Әхмәт Вәлиәхмәт улы МӨЛЕКОВ:

- Безгә Норлат - Тимерлек, Максимкинога кадәр, Аксубайга һәм Әлки районы чигенә кадәр юллар беркетелгән, мөмкинлеккә карап крестьян - фермер хуҗалыклары ассоциацияләренең үзәк усадьбаларына килү юлларын тәртиптә тоту йөкләнгән.

Барлык кирәкле техника комплексы хәрәкәттә, кар көртләре юлга салган очракта аларны чистартуны иртәнге 3 сәгатьтән башлыйбыз, кирәк булса тәүлек әйләнәсенә дә эшләргә әзербез, эшчеләргә җылы тукталыш урыннары, вахта машиналары бар, ә кадрларыбыз тәҗрибәлеләр, шуңа да бу мәсьәләдә проблемалар булмас дип уйлыйм.

МППның баш инженеры Әсгат Мансур улы АБДРАХМАНОВ:

- Барлык юл техникабыз да төзек: алгы көрәкле ике экскаватор, С - 130, МТЗ - 80, МТЗ - 82, Т - 25 тракторлары һәм үзбушаткыч машина. Эшче график әзер, җаваплы кешеләр беркетелгән. Тимер юлчылар микрорайонында һәм шәһәрнең үзәк өлешендәге тротуарларда тәртип булдыру өчен барысын да эшләячәкбез.

НУАД начальнигы Һади Харис улы САДЫЙКОВ:

- Бездә шактый куәтле техника тупланган: кар чистарту һәм ротор техникасы, кар «пробкаларын» чистарту өчен махсус машиналар, 5 бульдозер, 3 грейдер исәпләнә. Кискен ситуацияләрдә УТТдан да техника алырга була. Ягулыгыбыз җитәрлек, кадрларыбыз әзерлекле, өлкән мастерлар В.Багаев, З.Миназов һәм М.Сираҗетдинов үз вазифаларын белә. Ял һәм бәйрәм көннәрендә идарәдә тәүлек әйләнәсенә дежурлык оештырыла, кирәк булган очракта эш белән идарә итү өчен оператив штаб булдырабыз. Эш күләмебез зур булса да (шәһәр юлларыннан тыш без Иске Чаллы, Яңа Иглай, Ивашкино, Елховога һәм «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгына кадәрге, шуңа өстәп бөтен промысел юлларын карыйбыз), юлларны тулы тәртиптә тоту өчен үзебездән торганның барысын да эшләячәкбез.

Приз Дамирга кайтты

«Чаян» журналының 11 - 12 саннарында мәшһүр болгар футболчысы Христо Стоичков турындагы язма белән бергә фоторәсем чыккан иде. Журнал викторина рәвешендә Иҗоның кайда икәнлеген төгәл әйтүчегә Болгария командасы футболчыларының портретлары төшерелгән күн туп вәгъдә итте.

Җавап җибәрүчеләр арасында Норлаттан Миннегалиевлар гаиләсе дә бар иде. Гаиләнең ир - атлар өлеше һәрберсе җавапка үз версиясен тәкъдим иткән иде. Әти кеше Гомәр Әхмәтвәлиевич белән кече уллары Динар ялгышкан, аның каравы, тугызынчы сыйныфта укучы Дамир җавашның иң дөресен юллаган булып чыкты. Ул гына да түгел, 16 автор арасында әлеге затлы футбол тубы Дамирга насыйп булды.

Хәзер туп Миннегалиевлар гаиләсендә иң кадерле урында саклана. Дамирга килсәк, ул - спортка бик хирыс егет булып үсеп килә. 2 ел инде ул өстәл теннисы буенча район ярышларында катнашып призлы урыннарны яулый. Футбол белән дә яшьтән шөгыльләнә. Үзе укый торган 1 нче мәктәп командасында да уйный, НУРБ командасы составында да чыгыш ясый, даими рәвештә тренировкаларга йөри. Викторинада откан затлы тупка килгәндә, кем белә, бәлки ул Дамир Миннегалиев киләчәктә ирешәчәк зур - зур призларга юл ачасы беренче отыштыр?

Кышлату ничек бара?

ДУҢГЫЗЛАРГА КАРАШ... ДУҢГЫЗЛАРЧА

... Иде

Безнең мәгълүмат: 1990 нчы елда хуҗалыкта җәмгысе 3.200 баш дуңгыз баласы алынган. Бу һәр 100 баш төп анага 2133 баш туры килә дигән сүз.

«Төрнәс»нең дуңгызчылыктагы мактаулы эшләре белән гөрләгән чаклары бар иде. Кечкенә бер поселокны хәтерләтүче дуңгызлар абзарлары терекләр белән шыплап тулган иде. Чучкаларның рационын тулы кыйммәтле итү өчен азык та мул хәзерләнә иде. Маллар көр үсә, алар аз үлә, шуның нәтиҗәсе буларак, хуҗалык дәүләткә саткан итнең яртысын дуңгыз ите алып тора иде.

... Хәзер

Безнең мәгълүмат: бүген товарлыклы - дуңгызчылык фермасында 1373 баш мал асрала. Узган ел һәр 100 төп ана дуңгыздан 1105 баш дуңгыз баласы алынган. Былтыр 261 баш мал үлгән.

Бүген биредә башка күренеш. Дуңгызлар асрала торган абзарларның кайсылары бөтенләй «ташланган», икенчеләре яртылаш буш. Малларның баш саны да берничә тапкыр ким. Хәер, абзарларның маллар тотыла торганнарында да аларны асрау өчен шартлар юк. 125 станок - урынга исәпләнгән бинада, мәсәлән, без булган көнне түбәдән тамчы тама, аралыклар, маллар читлекләре сыек тирес катнаш су иде. Вакыт әбәткә якынлашып килсә дә, абзардан тирес чыгарылмаган, хәтта аягын сузган маллар да читлекләрдә яталар.

- Ә бинаның салкынлыгы... Дер - дер калтыраучы дуңгыз балаларының кайберләре аналарына «сыенган», икенче берләре батареяга артларын төрткәннәр. Калорифер эшләп торса, бина җылы да, коры да булыр иде дә бит...

- Ул юк. Ягулык булмагач, мастерскойга запчастькә бирдек,- диделәр белгечләр.

Бинаны электр белән ягуга көйләү дә сәбәп булгандыр инде моңа. Берничә еллап элек зур абзарга стена буйлап электр батареялары сузганнар. Аларның гына дүрт рәтле абзарны җылытып бетермәве көн кебек ачык юксa. Бигрәк тә хуҗалыкта утның да еш сүнүен белгән хәлдә.

Әмма читлекләргә салам түшәп булса да, малларны азрак «җылытып» булыр иде. Яңа туган һәм, гомумән, өч айгача булган малларның күпләп үлүенә дә юл куелмас иде, мәгаен.

Хәер, малларның нормаль асралуына киртә булып торучы тагын бер сәбәп бар әле. Анысы ашату. Гәрчә ферма бригадиры Зәкиулла Фәйзуллин үзе азык җитәрлек дисә дә, хуҗалыкта бер грамм да катнаш силос, бәрәңге хәзерләнмәгәндә, катнаш азык, сирәк - сирәк кенә аертылган сөт, «үләм» дип аяк сузарга җыенучыларына гына яхшы сөт биреп кенә әллә кая китеп булмый шул. Ә бит абзарлар янына ук траншеяларга күп итеп югары сыйфатлы катнаш силос хәзерләп, малларны бер кайгысыз кыш чыгарган елларны күпләр хәтерли булыр.

Гомумән, дуңгызчылыкта эш үзагымга куелган. Материал һәм акча юклыкны сылтау итеп, быел җәй биредә берничә бинада агарту эшләре башкарудан кала, абзарларны ремонтлап, бармакка бармак та сукмаганнар. Кайчандыр реконструкция ясала башлаган биналарда да эш азаккача җиткерелмәгән. Тирес чыгару транспортерларының байтагы 10 - 12 еллап алыштырылмаган. Быел насосның сафтан чыгуы нәтиҗәсендә торбалар туңган, терлекчеләр сусыз да интеккәннәр.

Фермада нәсел эше дә үзагымга куелган. Биредә малларны турлап балалатуга хәзерләү турында да күптән онытканнар. Ветеринария эше дә тиешле дәрәҗәдә түгел.

- Акча булмау сәбәпле дәвалау средстволарын да сатып ала алмыйбыз,- ди ветеринария табибы Владимир Семенович Енилин.

Гомумән, товарлыклы - дуңгызчылык фермасында эшлиләр, менә аның нәтиҗәсе дип күрсәтерлек нәрсә юк һәм моның кайчан буласын төгәл итеп әйтеп бирүче дә табылмады. Бик кызганыч...

Р.ГИНЯЕВА.

Синең кешеләрең, магистраль

Кыю, вакыты белән хәтта дорфа, үз хаклыгына ышанганда ныык, тынмас, фикерен белдергәндә туры, бер үк вакытта сизгер, тирә - юньдәгеләргә игътибарлы, кешеләр белән аралашуда гади. Әмма кирәк чакта кырыс, бигрәк тә юл мәнфәгатьләренә кагылганда хакимлек итәргә яратучан да була белә. Юллар - аның бөтен тормышы, ул инде үзенең аннан аерылгысыз булуын күптән аңлады. Чыннан да, Любовь Никифоровна Газизуллина аның бөтен тормышы хезмәткә һәм кешеләргә багышланган дип әйтерлек сирәк җитәкчеләр токымыннан.

Бу көннәрдә аны юбилее белән күпсанлы котлауларга без, редакция хезмәткәрләре дә кушылабыз, Любовь Никифоровнаның киләчәктә дә шулай тормыш сөючән, яшь күңелле булып калуын телибез. Бүген газетабызда даими авторларыбызның аның турында язмаларын уртак баш астында берләштереп бирүебез тикмәгә түгел: алар һәр икесе эшлекле, кеше мәнфәгатенә хезмәт итәргә әзер торган депутат һәм җитәкчегә тирән мәхәббәт һәм соклану хисләре белән сугарылган бит.

СТАНЦИЯ НАЧАЛЬНИГЫНЫҢ

Бер көне... Һәм бөтен тормышы

6.30. Эш көне әле башланмаган, ә телефоннар инде чылтырый.

- Әйе, әйе, тыңлыйм сезне. Әйе, вагоннар бирәбез...

6.45. Планерка. - Исегезгә төшерәм, юлда поездлар хәрәкәте һәм хезмәтне саклау буенча гадәттән тыш хәл күзәтелә, игътибарлы булыгыз. Безнең бүлектә соңгы көннәрдә генә дә өч ЧП булды. Бүгенгә бирем: 5 вагонны - бөртеккә, 3 не - нефтькә, 12 не - патокага, 2 не - металлоломга. Сораулар бармы? Юк. Эшкә.

7.10. Үткән тәүлек өчен отчет.

7.30. Кабинет янында кешеләр. - Без сезнең янга, Любовь Никифоровна. Зинһар, Самарадан кирпеч алып кайтырга машина табыштыруда булышыгыз. Телефон аша әле тегендә, әле монда шалтырата. - Егетләр, машина кирәк. Иртәгә. Пенсионерларга ярдәм итәсе иде. Булыр? Рәхмәт. Булды, апайлар, барыгыз, алып кайтыгыз.

8.00. Хакимият башлыгы чакыра. Торак фондын МПП балансына тапшыру мәсьәләсе хәл ителә.

9.00 - 10.20. Селектор киңәшмәсе. Бүлекчә җитәкчелегенә эш нәтиҗәләре җиткерелә. Гыйнварның беренче декадасында станция йөк төяү - бушату буенча айлык заданиене 50 процентка үтәгән. Отделениедә хәл мөшкелрәк. Өстәмә задание бирелә - 600 тонна.

11.00. Төшке ял. Әмма станция буенча дежурный шалтырата. 909 поезд кузгалып киткәндә туктатырга мәҗбүр була: ябык переездга «Жигули» керә. Ачыкларга китте.

14.00. Пенсионер Мельников керә. Пионерская урамында 2 көн су юк. Ремонтчыларга шалтырата. Ашыгыч чаралар күрелә.

14.30 - 16.00. Телефон, телефон. Предприятие җитәкчеләре белән йөк күчергән өчен түләүләр турында сөйләшү. Клиентураның станциягә 5 млрд сум бурычы бар.

Ә үтенечләр кимеми: вагоннар бирегез.

16.10. Алексеевск районыннан «Сельхозхимия» рәисе ашлама кайтартуда булышуны үтенә. Мәсьәлә хәл ителә - 9 вагон җибәрелә.

Хезмәт ветераны пенсионерка Коннова дәвалауда ярдәм итүне сорый. Үзәк шифаханәнең бүлек мөдире Фомина белән сөйләшеп, ул стационарга урнаштырыла. Көн дәвамында кергән почта белән таныша, төрле документларга кул куя, станция буенча дежурный белән элемтәгә кереп, эш барышын контрольдә тота.

Көн нәтиҗәсе: задание үтәлгән. Бөртек, нефть, патокага 12 урынына 16 вагон бүленә, металлоломга - 2 урынына 4, планнан тыш 1 вагон коры сөткә бирелә.

18.45. Планерка. Яңа смена дежурлыкка керешә. Техника куркынычсызлыгына игътибар бирелә. Салкыннар көчәю белән рельсларның ярылуы ихтимал. Поездлар хәрәкәт графигына контрольне көчәйтергә.

СОҢГЫ СҮЗ. Җентекләбрәк язганда да булыр иде. Бер сүз белән әйткәндә - көне буе тәгәрмәчтәге тиен төсле...

Хронометражны И.САНДЛЕР алып барды.



Бу хатын - кызны Норлатта белмәгән кеше юктыр. Л.Н.Газизуллина 35 ел буе станция коллективы белән җитәкчелек итә, һәм бу аның өчен актив, иҗади хезмәт еллары саналалар.

Норлатка Уссурийск тимер юл транспорты техникумын тәмамлап килде. Коллективта эшли башлауга белеме җитмәүне сизеп, читтән торып Ульяновск пединститутын бетерде. Яңа җитәкчене кешеләр бик тиз үз иттеләр, ышандылар. Шуңа ул район Советының алыштыргысыз депутаты булды, ә 1990 - 95 елларда Татарстан Республикасы Югары Советында халык вәкиле иде. Шул чорда депутат Любовь Никифоровна тырышлыгы белән үзәк шифаханәдә тудыру бүлеге төзелә башлады, Норлат - Казан поезды җибәрелде. Тимер юлчылар поселогында газлаштыру башланды һәм урамнарны асфальтлау тәгәлләнде, Кондырчадан су китерү линиясе төзелү мәсьәләсе көн тәртибенә куелды.

Районда тимер юл транспортында эшләгән хатын - кызлардан беренче булып СССР юл Министрлыгы тарафыннан аңа «Мактаулы тимер юлчы» исеме бирелде. Чыннан да, аның куйган хезмәтләре күз алдында. Станциягә ул җитәкчелек иткән елларда яңа механикалаштырылган, техник чараларның барлык җыелмасы белән җиһазландырылган двор төзелде, анда үк яңа товар конторасы да бар. Йөк составларын кабул итү өчен элек 10 юл бар иде, ул инде йөк күчерүләрнең күләме үсү сәбәпле станция ихтыяҗын канәгатьләндермәде. Л.Н.Газизуллина йөк поездларын кабул итү өчен транзит паркы төзүгә алынды һәм аны кыска срокта файдалануга тапшырды. Ә хәзер аның йөрәген тимер юлчылар поселогын газлаштыру мәсьәләсе ныык борчый. Газ белән эшли торган котельняны да озакка сузмыйсы иде. Кешеләр өчен ышанычлы җылылык үзәге булырга тиеш бит!

- Акча җитмәү сәбәпле, котельняны тапшыруны 1997 ел планына кертергә туры киләчәк. Ул исә тимер юлчылар микрорайонын тулысынча, «Сельхозхимия», «Коопстрой» төзелеш оешмасы, элеваторның 2 нче дворы кебек промышленность объектларын җылылык белән тәэмин итәргә, берочтан 90 фатирлы йорт төзелешен башларга мөмкинлек бирәчәк.

Тимер юлчылар аның сүзенә ышаналар. Моңа нигез дә бар. Күптән түгел генә әле ул элеккеге машинистлар сугыш ветераннары И.З.Нургалиев, Ф.И.Альбицкий, З.Хәйруллинга фатир бирү өчен средстволар алуга иреште. 40 фатирлы яңа йортның 24 фатиры, МСО белән үзара исәп - хисап нигезендә, шулай ук тимер юлчыларга булачак. Любовь Никифоровна инде яңа 90 фатирлы йорт турында хыяллана. Бу бит тимер юлчылар өчен дә зур куаныч!

Ә Норлат станциясе элеккечә үк эшлекле кәефтә хезмәт куя. Юл һәркемгә хезмәт ритмы бирә.

А.СПИРЧАГОВА.
Норлат шәһәре.

02 хәбәр итә

Шифаханә белән тәмамланды

Яңа Тумба авылыннан А. һәм аның дуслары А. һәм Е. өчен Яңа ел озак онытылмас. Бик каты бәйрәм иткәннән соң элеге салмышлар компаниясендә сугыш чыга. А. балта эләктереп шешәдәшләренә ташлана. Башлары яраланган А. һәм Е.ны район үзәк шифаханәсенә китерергә туры килә.

КамАЗ табылды

Фома авылында яшәүче берәүгә КамАЗның яңа хуҗасы булып озак яшәргә туры килми. Октябрь эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре көче белән машина күрше Кошки районында бик тиз табылды. Машина куучы ачыкланды, аны хәзер эзлиләр.

Коралланган, димәк, куркыныч

Соңгы көннәрдә сводкаларда законсыз корал саклау турында хәбәрләр керде. Мәсәлән, шушы көннәрдә генә норлатлыларда 3 обрез һәм бер РГД - 5 гранатасы табылды. Тикшерүчеләр аның нинди максатка саклануын ачыкламый калмаслар, әлбәттә.

Гаебен үзе таныды

Октябрь эчке эшләр бүлегенә гражданин М. килеп 1996 елның май аенда дусты Б.белән коммерция киоскасын талаулары турында хәбәр итте. Алар 6,5 миллион сум, сигарет һәм шампанскоелар урлаганнар. Җәза ни бәяг... төшәр икән?

Рольләр ачыклана

Ике норлатлы урлап баймакчы булалар. Шәһәрнең Молодежная урамында тәрәзә рамын ватып фатирга керәләр, телевизор, видеомагнитофон, пылесос һәм башкаларны урлыйлар. Әмма жинаятьчеләр табышлы эшне «юарга» гына өлгерми калалар: кулга алыналар, урланган әйберләр кайтарыла. Инде һәрберсенең жинаятьтәге роле ачыклана.

Газ куркыныч шул

Бу хакта күп мәртәбәләр искәтөшерелсә дә, газдан файдалану кагыйдәләрен үтәмәүчеләр бәла күрә торалар. 11 нче гыйнвар көнне кич белән Абрыскино авылында шуның нәтиҗәсендә М.ның йорты янды. Хуҗа кеше үзе дә янгыннан алган җәрәхәтләреннән шифаханә юлында вафат булды. Янгын сәбәпчесе караучысыз калдырылган газ плитәсе булган.

«Дуслык» газетасы хәбәрчеләре арасында Исхак ага Шәйхиевның үз йөзе, үз урыны бар. Озак еллар дәвамында ул хезмәт сөючән авылдашлары, аларның уй - мәшәкатьләре турында безгә җиткереп тора. Язмаларында әхлакый теманы үз итә, еш кына якташларын борчыган проблемаларны күтәрә. Гыйнвар ахырында даими авторыбызга 60 яшь тула. Аны юбилее белән котлап, чын күңелдән ялыкмас йөрәгенә көч - дәрман, тутыкмас каләменә яңа иҗади табышлар, исәнлек, бәхет телибез һәм укучылар игътибарына аның чираттагы язмасын тәкъдим итәбез.

УҢЫШКА БУЛСЫН ИДЕ

Узган ел Зирекле авылы өчен бер яңалык белән төгәлләнде: хуҗалык үз ризалыгы белән, тулы килешү нигезендә «Путь к коммунизму» КХАсы белән кушылып көн итә башлады. Хуҗалык рәисе итеп В.И.Гаврилов сайланды.

Яңа колхоздашларыбыз безнең өчен чит - ят түгел иде. Бу ике төбәк халкы элек - электән үзара дус, аралашып яшәгәннәр. Аларга дип аерымлыгы да, милләт тәрлелеге дә гаиләләре белән дуслашып яшәргә комачауламаган. Ике авылның да өлкән буын кешеләре арасындагы тамыр алган элемтә бүгенге көнгә кадәр сакланган. Безнең Зирекле авылы Биляр Озеро кырларына кереп урнашкан, янәшәлек шулай ук безгә кыр эшләрендә бер - беребезгә ярдәмләшеп, булышып яшәргә мөмкинлек бирде. Без шулай яшәдек тә.

Ике авыл арасындагы бәйләнешнең күптәннән нигуына китергән тагын бер сәбәп бар: Биляр җәрәдә элек - электән базар эшләп килгән. Анда мал - туар да, һөнәрчелек әйберләре дә, яшелчә - җиләк - җимеш тә һәммәсе дә сатылган. Зирекле, Бикуле, Кәкре Атау, Кара Күл, Иске Авыл, Чулпанда яшәүчеләр сатасын сатарга, аласын алырга шунда йөргәннәр. Бу исә халыкның үзара тыгыз бәйләнешенә, бер - берсен якыннан белүенә шулай ук үз йогынтысын ясаган. Инде сүз шунда җиткәч, халыкның бер фикерен дә җиткерәсем килә: шул авыл базарын яңабаштан яңартмаска микән? Ул бит хәзерге алыпсатарлар базары түгел, халык үзе җитештергән, үзе эшкәрткән, үзе ясаган һәм авыл кешеләре өчен бик кирәкле әйберләрне туплаган базар иде. Шәт хәзерге һөнәрчеләребез дә җиң сызганып эшкә керешерләр иде. Бәлки бу фикергә яңа берләшкән хуҗалык җитәкчелеге колак салыр, халык моңа бик шат булыр иде.

Инде хуҗалыкларның берләшүенә килгәндә, халык бу берләшүдән уңай нәтиҗәләр көтә. Ул шулай булсын да иде.

...Сабир атлы көрәшче бар

Их, ул яшь чаклар! Әй түбәләреннән тамар чаклар җиткәндә егет - жилән бергә җыелдымы - авызларында бер сүз була иде: озакламый ташулар агар чак житә, ә аннан соң инде сабантуйга санаулы көннәр генә кала. Бозлары күтәрелеп, ярларыннан ташып агучы Чирмешән буена кардан беренче булып арынган юлга кадәрле җирдә, көрәш сезоны ачыла иде. Сабир беренче тапкыр көрәшче буларак 1951 нче елда чыкты яр буена. Севастопольдә хәрби хезмәт вакытында татар егетләре белән бил алышуы бик мавыктырган иде шул аны. Ә инде биредә беренче елны ук Сабантуй батыры Мөнир Әндәржановны аркасына яткызгач, үзендә мөмкинлекләр күп булуын чамалап, көрәшне киләчәктә дә ташламады. Хәтта бер чак Чулпан көрәш мәйданын тарсына да башлады. Кыюлыгын җыеп, район Сабантуе көрәш кәләмәнә чыкты. Омтылышы бушка булмады. Өч ел рәттән район сабантуе батыры исемен яулады Сабир. Баулыда да бер елны мәйдан тотып, бик җиңеллек белән сабантуй тәкәсенә ия булды. Бер ел соңрак Бөгелмәдә механизаторлар хәзерләү курсында укыганда шәһәр күләмендә абсолют батыр исемен алды.

- Кешенең көрәш гомере озын булмый,- дип искә ала Сабир ага Мәйданны калдырып киткән көннәрен - дүрт дистә елны ваклап килгәндә көрәшче буларак тарихыма нокта куйдым. Яшьләргә юл бирәсе килде...

Нәкъ шул елларда бердәнбер улы Хәбир дә көрәшче буларак формалашып килә иде инде.

Кабул ителгән карары җитди булса да, спортка, аеруча аның милли төре - көрәшкә һичкайчан битараф булмады ул: һава шартларының нинди булуына карамастан сабантуйның берсен дә калдырмады, таныш булган һәм булмаган көрәшчеләр өчен башыннан азагынача борчылып, көеп утырды. Ә инде туган авылында көрәш осталары үсүенә, аларның осталыгы камилләшә баруга чын йөрәгеннән шатланды:

менә бит нинди әйбәт шөгыль таптылар егетләр. Шулар өчен хәтта үз, шәхси призын да булдырды. Инде менә икенче ел мәктәптә аның призына махсус ярышлар үткәрелә. Узган елдагысы район ярышчыларын җыйса, быелгысы республика күләмендә үтте.

Яңа ел алдының зәмһәрир суык көннәренең берсендә үтте бәйге. Ярышка командаларның байтак җыелуы үзе үк яшьләрнең милли көрәш белән чын - чынлап кызыксынулары турында сөйли иде инде. Ызандаш Чирмешән районыннан бәйгедә 2 команда катнашты. Аксубай, Бөгелмә районнары яшь спорт сөючеләрен дә салкыннар куркытмады. Үзебезнең районнан да көрәшчеләр күп килгән иде бәйгегә. Шулай итеп, Чулпан мәктәбе спорт залына 70 тән артык көрәшче җыелды. Аларның дәртле көй астында залга үтүләре, районның республика күләмендә танылган көрәшчеләре Илгиз Әндәржанов (Чулпан) һәм Рәнис Рәхмәтуллинның (Түбән Норлат) ярышлар әләмен күтәрүләре, мәктәп үзешчәннәренең музыкаль сәламнәре көрәшчеләргә дәрт - дәрман өстәми калмагандыр. Ярышларны ачкан район хакимияте башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова да командаларны сәламләп, аларга уңышлар теләде.

Ул көнне байтак чулпанлыларның көне файдалы - чын мәгънәсендә матур профессиональ көрәш карап үтте. Унбер үлчәү категориясе буенча үткәрелгән ярыш биш сәгатькә сузылды бит. 10 - 14 яшьлекләр арасында Киекледән Илфат Хәсәншин, Түбән Норлаттан Рәнис Рәхмәтуллин, Рәшит Газизов, Чулпаннан Фәргать Фәйзуллин, Эмиль Ибраһимов, Югары Норлаттан Руслан Кәбиров, Чирмешәннән Сергей Григорян чемпион исемен яуласалар, 15 - 18 яшьлекләр арасында иң күп призерлар ярыш хуҗалары булдылар. Илгиз Әндәржанов, Фәнис Вәлиев, Ильяс Садыйков - Чулпанның горурланырлык егетләре булуларын тагын бер кат расладылар. Хафиз Вәлиев (Түбән Норлат), Айрат Мусин (Югары Норлат) та үз үлчәү категорияләрендә җиңүче булдылар. Ә ярышларның абсолют батыры исемен чулпанлы Ильяс Садыйков яулады һәм бәйге химаячеләренең берсе - «Чирмешән» КХАсы тәкәсенә лаек булды, ә гомумкоманда нәтиҗәләре буенча чулпанлылар беренче урынга чыксса, Түбән Норлат командасы икенче, чирмешәнлеләр өченче урын яулады.

- Сезнең белән чын - чынлап горурланам мин, егетләр,- диде чемпионнарга, командаларга бүләк тапшырганда ярыш «гаеплесе» - Сабир ага Хәбибуллин,- киләчәктә дә шундый гаярь, көчле булыгыз.

- Оста көрәшчеләрдән илебез терәге булырлык яхшы кешеләр дә үсеп чыгар дип ышанам,- диде бәйгене йомгаклауда катнашкан район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин.

Озак еллар Татарстан Республикасында спортның милли торләре буенча федерация рәисе булып торган һәм үз гомерендә аз ярышлар күрмәгән Фатыйх Сәүбәнович Чулпанда үткән бәйгегә югары бәя биргән икән, димәк, чыннан да, ярышлар югары дәрәҗәдә үткән һәм бу яшь спортчылар осталыкларын камилләштерүгә тагын бер адым ясаган дигән сүз.

Бәйге хуҗалары - чулпанлылар әлеге чараны бөтен ваклыкларына кадәр уйлап, үрнәк оешканлык белән үткәрделәр.

- Биредә икенче тапкыр, булам, октябрьләрнең милли көрәш белән кызыксынулары, осталыклары артуы күңелемдә соклану уята, уңышлар аларга,- диде әңгәмә вакытында Бөгелмәдән килгән тренер Рәис Садыйков.

- Максатчаннар,- диделәр Чирмешән районы вәкилләре. Команда «йөрәгә» яшь спортчылар белән республика, Россия илләре буенча ярышларга йөреп, чулпанлыларның спортчылар буларак даннарын ныгытучы тренер Расыйх Сәмигуллин турында әйтүләре иде бугай шулай. Булдыра шул Расыйх. Әнә бу ярышка күпме химаяче тапкан. Район хакимияте һәм «Нирмешән», «40 лет Победы» КХАсы, җирле үзидарә, мәктәп, район мәгариф бүлеге, «Нефть - инвест» компаниясе, орлыкчылык станциясе шушы авыр заманда да спортчыларны кызыксындыру өчен хәлләреннән килгәнчә ярдәм иттеләр.

... Өч дистә ел гомерен комбайн штурвалы артында үткәргән, бүген дә җир белән элемтәсен өзмәүче районның тәҗрибәле фермеры, өлкән яшьтәге көрәшче, ахыр чиктә зирәк акыллы, шул ук вакытта үтә тыйнак ил агасы кеше булган Сабир ага Хәбибуллинны шулай хөрмәтләүләре иде аларның.

Р.ГИНЯЕВА.

- «Банкка мәктәп эскәмиясеннән килдем». Асия Фатыйховна үзе турында шулай дигәч, шаяртадыр дип уйлап куйган идек. Юк икән. Чыннан да, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң ул Дәүләт банкында кассир - бухгалтер булып эшкә урнаша. Асия исәп - хисап өлкәсен үзенең гомерлек һөнәре итәргә шунда карар кыла да: икенче елны ук Казан финанс - экономика институтына укырга керә, аны тәмамлагач, янә банкка эшкә кайта. Ул елларга инде 18 ел гомер үткән. Хәзер Асия Фатыйховна «Агропромбанк»ның кредит бүлеге начальнигы. Районның барлык ресурслары биредә тупланган. Банктагы кредит комитеты аны ихтыяҗ - сораудан чыгып бүлә генә, ә эшнең бар кухнясы - шушы бүлектә. Кредит үзәк банк ставкасы буенча билгеләнә. Ул хәзер 48 процентка тигез.

- Бу - кулланырлык ставка,- ди Асия Фатыйховна. - Без аның 210 процентка кадәр җиткән чакларын хәтерлибез.

Кредит бүлеге заманча банк бинасының иркен бүлмәсендә урнашкан, ике ел инде биредә компьютердан файдаланалар. Бүлектәгә 5 хезмәткәрнең һәрберсе үз эшен нечкәлекләренә кадәр өйрәнеп өлгергәннәр инде. Асия Фатыйховна исә үз кул астындагылардан тәртип, дисциплина, төгәллек таләп итә, чөнки финанс эшендә болар - иң тәҗрәл сыйфатлар. Грамоталы, тәҗрибәле бүлек начальнигын банкта нәкъ шул сыйфатларга ия булуы өчен хөрмәт итәләр дә. Асия ханым - ике бала анасы, хуҗабикә буларак та ихтирамга лаек.

«Банк минем өчен туган йорт сыман»- дип кабатларга ярата ул. 18 ел гомерен шунда хезмәткә багышлаган А.Ф.Садыйкова шулай әйтергә бик хаклы.

Рәсемдә: А.Ф.САДЫЙКОВА.

Редакциягә хат килде

Телефонга бик мохтаҗбыз

Мин гаиләм белән 36 ел буе шәһәребезнең тимер юлчылар поселогындагы Горький тыкрыгында яшәдем. Үзем Бөек Ватан сугышында катнаштым, II группа инвалид. Хатыным да II группа инвалид. Икәү бергә Дауна авырулы, яшьтән беренче группа инвалид улыбызны да тәрбиялибез. Аңлашыла ки, безгә шифаханәгә еш мөрәҗәгать итәргә туры килә. Поселокта яшәгәндә күршеләребездә телефон бар иде, ул - бу булганда йөгереп керә идек аларга. Картлык баса башлагач, мин район элемтә узелы, тәэминат бүлегенә өемә телефон керттерү мәшәкате белән йөри башладым. Беренчесенә гариза язып кайтуыма да биш еллап гомер үтте.

Соңгы вакытта без яңа фатир - Карл Маркс проспектындагы өченче йортка күчкәч, телефон булмау үзен аеруча сиздерә башлады. Янәшә - тирәдә яшәүче кешеләрнең күпчелеге яшьләр, миңа таныш түгел кешеләр. Шуңа кирәк булганда мөрәҗәгать итәр кешем дә юк. Телефон булса, шифаханәгә генә шалтыратыр идем, дип уйлаган чакларым бик күп була. Алда телгә алган оешмалар җитәкчеләре яннарында булганда да шул турыда еш әйтәм. Әмма, кем әйтмешли, ач кайгысын тук аңламый шул инде ул. Ә бәлки сез бу эшне үз урыныннан кузгатырга ярдәм итәрсез.

В.САКАЕВ.

Норлат шәһәре

Әлеге хат уңаеннан без телефон аша район элемтә челтәре начальнигы Р.Ә.Җиһаншин белән элемтәгә кердек: **«Хат авторы яши торган йорт техник шартлар үтәлмичә, икенче төрле итеп әйткәндә, телефонлаштыру кабельләре тартмыйча файдалануга тапшырылган. Аңлашыла ки, якын киләчәктә хат авторына телефон кертү мөмкинлегебез дә юк»**, диде безгә узел җитәкчесе.

РЕДАКЦИЯДӘН: Менә шундый җавап сезгә, Сакаев иптәш. Зинһар өчен бу хәбәрне күңелегезгә авыр ала күрмәгез. Хәлегезгә керешер өчен без сезгә үз киңәшебезне дә юлларга булдык. Яңа йортта яшисез икән, күршеләрегез белән аралашу ягын карагыз инде. Сездән өстәге катларда телефоннары «гөрләп» эшләп торучы ачык күңелле, һәрчак сезгә телефон төрепкәсен сузарга әзер кешеләр белән дә танышыгыз. Ялгыш укыдым яисә газета корреспонденты ялгышкан дип уйламагыз тагын. Р.Җиһаншин әлеге йортларга телефон кертү мөмкин эш түгел дип ышандырырга тырышса да, сезнең йортта яшәүче аерым кешеләр байтак проблемаларын күптән инде телефон аша хәл итәләр. Ә сезнең кебек узел алдында «аерым хезмәтләре» булмаганнар чиратның һаман да азагында кала бирәләр. Ни эшләмәк кирәк, көчленеке замана шул...

САКЛАНМАВЫҢ КЕСӘГӘ ДӘ СУГА

«Күптән түгел шифаханәдә аборт ясаган өчен 200дән алып 300 гә кадәр акча түләргә кирәк, дип ишеткән идек. Моның сәбәбе нидә икән?
Роза М. Норлат шәһәре».

Мәсьәләне ачыклау өчен без район үзәк шифаханәсенең гаиләне планлаштыру мәсьәләләре өчен җаваплы, гинеколог **Лилия Әбдрәшитовна ДАУТОВАГА** мөрәҗәгать иттек.

Бүген газетада ул аборт ясаганнан соң хатын - кыз организмына никадәр зарарлы булуы турында сөйли, бу өлкәдә кайбер саннар һәм фактларны мисалга китерә һәм, әлбәттә, сорауга җавап бирә.

Ясалма рәвештә йөклелекне өзү яки аборт ясату еш кына хатын - кыз организмын аяныч нәтиҗәгә китерергә мөмкин. Күзәтүләр буенча ачыкланганча, гинекологик авырулардан җәфаланучы хатын - кызларның өчтән бере бик яшьли аборт кичергәннәр, һәр дүртенчесе бу операциядән соң җенси органнарга бәйле авыруларның катлауланыуы белән иза чигәләр һәм күп вакыт бала таба алмыйлар. Бүгенге көндә хатын - кызлар консультациясенә мөрәҗәгать итүче пациентларның 60 - 65 процеенты җенси органнар чире белән интегә, шуларның 30 процеенты гинекология бүлегенә дәваланырга җибәрелә. Аборт, аеруча беренче йөклелектә, баланың вакытыннан алда тууын ике тапкыр ешайта, аның аркасында 1,5 тапкырга күбрәк балалар һәлак була. Аборт ясату организмның саклану көчен киметә, яралгы өчен микрофлора нормаль булмаган хәлгә килә һәм шунлыктан йөклелек вакытында бала гарипләнә яки үлә. 1996 нчы елда район үзәк шифаханәсендә 766 аборт һәм 195 мини - аборт ясалды. 11 ай мәгълүматлары буенча шуларның 25е 16 яшьтән 19га, 413е 20 дән 34 яшькәчә, 152дән күбесе 35 яшьтән өлкәнрәк хатын - кызларга ясала. Беренче тапкыр балага узучы 20 хатын - кыз да йөклелекне өзүне кулай күрәләр. Нәтиҗәдә гинекология бүлегендә 212 йөкле хатын бала төшү куркынычы диагнозы белән дәваланды, ә 53 сендә балаларны коткарып булмады. Аңлашылганча, аборт хатын - кызның исәнлеге, туачак баланың саулыгы, гаилә иминлегенә зур зыян белән яный.

Бүген яшүсмер кызлар сәламәтлеге гадәттән тыш проблемага әйләнде. Ул аларның йөклелектән саклану чараларын белмичә яки игътибарга алмыйча, бик иртә җенси мөнәсәбәтләргә керүе аркасында барлыкка килә. Әлбәттә, моның нәтиҗәсе аяныч: ул көтелмәгән йөклелеккә илтә һәм иң күп очракта ул ясалма рәвештә өзелүгә дучар ителә. Шуңа күрә район үзәк шифаханәсендә бу җәһәттән күпкырлы эш алып барыла:

Гинекологлар мәктәпләрдә җенси тәрбияви лекцияләр укыйлар, район күләмендә 13 тән 15 яшькәчә кызларга карата профессиональ тикшерү үткәрелә, район үзәк шифаханәсенең, балалар поликлиникасында сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрендә чирләре булганнарга дәваланы мөмкинлеге бирелә. Хатын - кызлар консультациясендә яшүсмерләр өчен балага узуга каршы контрацептив чаралар бушлай бирелә. Шулай ук йөклелек тыелган хатын - кызлар өчен дә шундый ук фонд бар.

Яшүсмерләр өчен генә түгел, гомумән, хатын - кызлар арасында йөклелекне кисәтүдә төп чара булып исәпләнгән заманча контрацептив чаралардан файдалану хакында зур профилактика - агарту эшләре алып барыла. Тудыру йортында, гинекология бүлегендә, хатын - кызлар консультациясендә һәрбер хатын - кыз белән индивидуаль әңгәмәләр үткәрелә, чәршәмбе көннәрендә сәгать 9 дан 11 гәчә яшь әйләнешүчеләр белән әңгәмә оештырыла. 1995 нче елда «Дуслык» район газетасында контрацепциягә ләрнең төрле төрләренә кагылган мәсьәләләр яктыртылды. Ләкин, гаҗәпләнүебезгә каршы, бу аңлату эшләре барлык хатын - кызларның да җенси тормышында чагылыш тапмый. Ул гына түгел, ел агымында 4 - 5 тапкыр абортка килүче хатыннар да эш очрый. 1996 ел мәгълүматларына караганда, аналык эчендәге контрацептив чаралардан 28 процент гармональ препаратлардан бары тик 1,5 процент хатын - кыз гына файдалана. Шуннан чыгып, туу фактын теркәүнең төп алымы аборт дияргә мөмкин. Шуңа күрә гинекология бүлегендә дәүләт бюджеты карамагында һәм хуҗалык исәбендә яшәүче палаталар һәм ясалма рәвештә йөклелекне өзү буенча операцияләр үткәрү өчен хуҗалык исәбендәге гинекология бүлекләре ачу турындагы приказ нигезендә аерым категорияләргә (анонимлык, анестезиология ярдәме, эш аборт ясатучылар) түләүле абортлар үткәрелә башлады. Аларның бәясе 200 - 350 мең сумга кадәр. Инструкция нигезендә йөклелеге 22 атналык булган очракта социаль сәбәпләргә бәйле рәвештә кайбер хатын - кызларга бу операция бушлай каралган. Мәсәлән,

1. йөклелек вакытында иренең армия хезмәтендә булуы;
2. хатын - кызның яки иренең тоткында булуы;
3. ана хокукыннан мәхрүм ителгәндә;
4. күп балалылык (балалар саны 5 тән артканда);
5. йөклелек вакытында аерылышу;
6. көчләү нәтиҗәсендә йөклелек;
7. балада гариплек күзәтелсә;
8. хатын - кыз организмының физиологик яктан җитлекмәгәнлеге сәбәпле операция түләүсез үткәрелә.

Бушлай аборт тиешле документлар нигезендә комиссия тарафыннан хәл ителә.

Хатын - кызлар консультациясендә үткәрелә торган мини - аборт элек тә түләүле иде. Аның бәясе 41.600 сум. Медицина, социаль күрсәткечләре буенча, медицина хезмәткәрләренә, контрацептив чаралар кулланган очракта килеп чыккан кимчелекләр булганда мини - аборт бушлай ясала. Шулай, үткән елда ясалган мини - абортларның 60 процеенттан артыграгы түләүсез үткәрелде.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: хатын - кызның ваемсыз рәвештә, тиешле саклану чараларын күрмичә теләмәгәндә - көтмәгәндә авырга узуы һәм аннан котылу чарасы итеп аборткa мөрәҗәгать итүе ике яклы зыян белән яный: беренчедән, сәламәтлеге нык какшый (һәм күбесенчә гомеренең соңгы көненә кадәр), икенчедән, гаиләгә дә матди зыян килә. Моны булдырмас өчен без кичекмәстән контрацептив чаралар турында белешмәләр алып, үзегезгә яраклысын сайларга һәм ике зыяннан да берьюлы котылырга киңәш итәбез. Ә без, гинекологлар ярдәмгә килергә әзербез.

РӘХМӘТ СЕЗГӘ

Чирләүнең ни икәнен белми идем мин. Гомер буе туктаусыз, ялсыз эшләп чыккангадыр инде, ул мине һәрчак читләтеп үтә килде. Әмма авыр хезмәт башкару үзен сиздерми калмый икән. Минем дә шифаханәгә эләгүем, алай гына да түгел, пычак астына ятуыма гомер буе көчтән килмәслек эш башкаруым сәбәп булды бугай. Ашыйсым ашаган, яшисем яшәгән дип, операциягә ризалашмаган да булыр идем бәлки. Әмма Иске Әлмәт участок шифаханәсе табибы Вячеслав Дмитриевичның акыллы киңәшләре, операция кирәклегенә ышандырулары мине үз тормышыма икенче күзлектән карарга мәҗбүр итте. Операцияне Вячеслав Дмитриевич үзе ясады. Операция сестрасы Лидия Зубова белән икәү алар мине савыктыру өчен зур көч куйдылар.

Шифаханәдә ике атналап яттым мин. Даими күзәтеп тордым: бер дигән, тырыш коллектив эшли биредә. Һәркем үз вазифасын җиренә җиткереп үти. Суфия Әхмәтҗанова белән Айнур Фәйзуллина, Альбина Насыйбуллина, Александра Шувалова турында исә аерым әйтәсем килә. Беренче икесе гомер буе авырулар өчен аш - су хәзерлиләр, Альбина исә - санитарка. Искиткеч җитез ул, аның куллары тигән җир ялт итеп кала. Яшьтәшем Александра да лаеклы ялда булуына карамастан, яшьләрдән һич калышмыйча эшли. Шул уңган, булган кешеләргә карап, аларның авырулар турында үз туганнарыдай кайгыртуларына сокланып, шуннан канәгатьләнү, үрнәк алып үземне яшәреп киткәндәй тойдым. Операциям дә уңышлы булды. Алтын куллы Вячеслав Дмитриевич Симцовка, шифаханә коллективына чын күңелемнән рәхмәт укыйм, хезмәтләрендә яңадан - яңа уңышлар, һәркайсына җан тынычлыгы, бәхет - шатлык телим.

С.ФӘТХЕТДИНОВА.
Яңа Әмзә авылы.

Укучыларыбыз иҗаты

Р.МӘСЛӘХОВА

Гөлсинәкәй

Чәчтәренне, Гөлсинәкәй,
Толымлап үрсән иде,
Өзелә бит үзәккәем,
Шуны бер күрсән иде.
Әй Гөлсинә, Гөлсинә,
Уйлап йөрим гел сине.
Ак каеннар көнләшерлек
Зифа буен, Гөлсинә,
Кара кашын, алсу йөзең
Керфекләрен гөл сибә.
Әй Гөлсинә, Гөлсинә,
Йөрәгемдә син генә.
Чибәрлегеңне көнләшеп
Ал чәчәк аткан яран,
Күзең сирпеп бер карасаң,
Төзәлә йөрәк ярам.
Әй Гөлсинә, Гөлсинә,
Яраттым сине генә.

Балыкчы Марсель

Марсель утыра дәрестә,
Тәрәзәгә дә карый,
Дәрес саен җәфа чигә,
Тәнәфес көтеп арый.

Тукта әле, укытучы
Балыкларны сөйли бит,
Тавышы да йомшак кына,
Җыр шикелле көйли бит.

Инде хыялында аның
Чирмешән яр буйлары,
Суларына кармак салып
Балык тоту уйлары.

Рәхәт тә соң җәй көнендә
Комда кызынган чаклар,
Чирмешәндә коенулар,
Эх, ямьле безнең яклар!

Шунда жилләр чәчен назлый,
Чирмешән дулкын кага,
Әтил суларына таба
Елга җәй тына ага.

Җәйге мизгелләрне уйлап,
Марсель изрәп киткән бит.
Каһәр төшкән, менә бәла,
Йоклар чиккә житкән бит.

Йокымсырап утырганда
Башын аска игән бит,
Укытучы килеп аның
Чәчен сыйпый икән бит.

***

Табигатьнең айсыз төне бар,
Болытсыз, кояшлы көне бар,
Сагышган саргайган көзе бар,
Тереклек туй иткән язы бар.

Табигатьнең тын - тын ягы бар,
Өермә - давыллы чагы бар
Кышында зәмһәрир салкын бар,
Җәендә ут кабар ялкын бар.

Каршылык, һәркайда каршылык:
Алларда дөреслек, ялгышлык;
Уйларда каранты, яктылык;
... Яшибез ашыгып, ашкынып...

белдерүләр

Норлат геофизик эшләр идарәсенә даими эшкә газ һәм электр белән эрәтеп ябыштыручы кирәк. Түләү - штат расписаниесе буенча.

***

«Дилижанс» кибете автозапчастьләр сата. Күчерү юлы белән дә түләргә була. Телефон: 2 - 19 - 77. 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр ялсыз эшлибез. Адрес: Норлат шәһәре, К.Маркс урамы, 12 йорт.

***

Урта белем турында 1982 елда Киекле урта мәктәбе тарафыннан Зарипова Роза Ранасовна исеменә бирелгән 663089 номерлы Б серияле аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга.

***

3 бүлмәле фатир ике 1 әр бүлмәлегә алыштырыла, вариантлар булуы мөмкин. 2 - 18 - 45 телефон буенча шалтыратырга.

***

Яшәп тору өчен фатир кирәк, телефонлы, шәһәр үзәгендә булса бик яхшы. Түләү - югары. Тел.: 5 - 27 - 39, 2 - 20 - 49.

***

Чистарту корылмалары тирәсендә гараж сатыла. 18 сәгатьтән соң 5 - 21 - 16 телефоны буенча Р.Р.Шәйхетдиновка мөрәҗәгать итәргә.

***

Чисарту корылмалары районында капиталь гараж һәм 1987 нче елгы «ЗАЗ 968М» автомобиле сатыла. Тел.: 5 - 11 - 52.

***

Ашгыч рәвештә әйбәт хәлдәге «Урал» мотоциклы сатыла яки иткә алмаштырыла. Адрес: Югары Норлат, Мөхәммәтов Шәрифуллага мөрәҗәгать итәргә.

***

Шәһәр үзәгендә 3 бүлмәле фатир сатыла яки килешү буенча Димитровград шәһәренә алыштырыла. Советская урамы, 77 - 1.

***

Ретранслятор районында гараж сатыла. Тел.: 5 - 18 - 10.

***

Норлат шәһәрендә бер бүлмәле фатир Самара шәһәрендә шундый ук фатирга алыштырыла. Адрес: 50 лет Победы урамы 3 - 10. (Иске заправка янында яңа йорт.)

***

6 га 4 үлчәмле чаналы яңа гараж сатыла. Адрес: Красин урамы, 8.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, жомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркатип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2047 данә. Заказ N 5134.